ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«СУГУШЛИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«СУГЫШЛЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Центральная ул., дом 27, село Сугушла,
Лениногорский район, 423281

Центральный урамы, 27 нче йорт, Сугышлы
авылы, Лениногорский район, 423281

Тел.: (8-85595) 3-81-91, факс: (8-85595) 3-81-91, Sugush.Len@tatar.ru, leninogorsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 31 октябре № 4

Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлеге Сугышлы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлеге Сугышлы торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2022 елның 19 ноябренә 10 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне распарга:

Сез 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Сугышлы авыл җирлеге Сугышлы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 нче группа инвалидлары, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләрдән, кендезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 (Биш йөз) сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

а) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру

- Сугышлы торак пунктында су линияләрен өзеклекләрне бетерү буенча эшләр;

б) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре булган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, инвалидлар өчен социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы һәм күрсәтелә торган хезмәтләр күрсәтү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен тезекләндерүне оештыру:

- Сугышлы торак пунктында (Үзәк урам, Гафиятуллин урамы, Гагарин урамы, Насосная урамы, Хәлиуллин урамы) урам утларына техник хезмәт күрсәтү;

- территорияне механикалаштырылган һәм кулдан үлән чабу буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, авария хәлендәге иске агачларны кисү (килешү буенча эшләрне түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Сугышлы торак пункты урамнарын (Үзәк урам, Гафиятуллин урамы, Гагарин урамы, Насосная урамы, Хәлиуллин урамы) кардан чистарту;

-Сугышлы торак пунктында юллардагы чокырларны ремонтлау (Гагарин урамы);

г) җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру:

- мәдәни-массакүләм чаралар уздыру өчен костюмнар сатып алу

д) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту:

- Сугушлы торак пунктында зиратларның коймаларын ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Сугышлы авылы, Үзәк урам, 27 йорт адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан кененнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Сугышлы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлыгы

А.П. Зыятдинова